Республика Татарстан
Менделеевский муниципальный район
Глава Ижевского сельского поселения
423647, Менделеевский район
с. Ижевка, ул. Советская, д. 25
тел. 8(85549) 3-67-89

Татарстан Республикасы
Менделеев муниципаль районы
Ижевка авыл жерлеге башкарма
Менделеевск районы
Ижевка авылы Совет урамы, 25
тел. 8(85549) 3-67-89

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ

**15.11.2025 ел** **№ 5**

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Ижевка авыл җирлегенең Ижевка авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлеге Уставының 22 ст. нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлеге Башлыгы

КАРАР БИРӘМ:

1. 2025 елның 25 ноябре 15.00 сәг. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Ижевка авыл җирлегенең Ижевка авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. 2025 елның 25 ноябре 16.00 сәг. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Ижевка авыл җирлегенең Ижевка авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә
3. Гражданнар җыенының барлык этапларын уздыру урыны итеп Ижевка авылы, Совет урамы, 26 йорт адресы буенча урнашкан Ижевка авыл клубын билгеләргә.

Ижевка авылы халкы исемлеген җыен этапларына бүлүне территориаль билге буенча түбәндәге тәртиптә башкарырга:

**Беренче этап**: Урман урамы, Болын урамы, Яшьләр урамы, Курорт урамы, Кояшлы урам, Яңа завод урамы, Чәчәкле тыкрыгы, Яңа завод тыкрыгы, Юбилей урамы, 1 йорт.

**Икенче этап**: Яр Буе урамы, Ветераннар урамы, Яшел урам, Совет урамы, Кыр урамы, Татар урамы, Курорт тыкрыгы, Мәктәп тыкрыгы, Ветераннар тыкрыгы, Яшьләр тыкрыгы, Юбилей урамы, 2,3 йортлар.

2. Гражданнар җыенында түбәндәге сорауны расларга:

"2026 елда Сез үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районы Ижевка авыл җирлегенең Ижевка авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, I-II төркем инвалидлардан, 18 яшькә кадәрге балалары булган аз керемле күпбалалы гаиләләрдән, югары һәм урта уку йортларының көндезге бүлегендә укучы студентлардан 500 сум күләмендә, ә махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларын азат итеп, кертергә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә ризамы?":

1. Һәйкәлләрне (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү: (Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәйкәлен ремонтлау һәм реконструкцияләү);

2. Торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү: ( үлән чабу, балалар мәйданчыгын койма белән әйләндереп алу, материал сатып алу һәм урнаштыру);

3. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту , җирлек эчендәге юлларны ремонтлау ( кар чистарту);

4. Су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау: ( канализация насос станциясен киртә белән тотып алу, материал сатып алу һәм урнаштыру) ?»

үткән җәен салу чараларының калдыкларын карны чистартуга илтергә

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм www Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында http:///mendsleevsk.tatarstan.ru "Ижевка авыл җирлеге" бүлегендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Менделеевск муниципаль районы
Ижевка авыл җирлеге башлыгы Р.Т.Мәсәгутова